РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЛАИШЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА ГОРОДА ЛАИШЕВО

422610 г.Лаишево,
ул.Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘР БАШЛЫГЫ

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт,
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**2025 елның «02» декабре** **8 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 мартындагы 2 номерлы карары, шәһәр башлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 июнендәге 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» һәм норматив-хокукый актларны туры китерү максатларында КАРАР ИТӘМ:

1.«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 мартындагы 2 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Шәһәр башлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 июнендәге 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Камская новь» район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш шәһәре җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик иминлек мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Шәһәр башлыгы** **И.Ф. Зарипов**